СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 264 от 09.11.2018
на № ________от ____________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының 2019-2021 елларга социаль-икътисадый үсеше фаразы турында.

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары – икътисад бүлеге начальнигы М. М. Баһмановның 2019-2021 елларга Саба муниципаль районының социаль-икътисади үсеше фаразы турында докладын тыңлап, фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары – Саба муниципаль районының 2019-2021 елларга социаль-икътисади үсеш фаразы турындагы докладын игътибарга алырга.

1. Төп юнәлешләр һәм максатлар итеп түбәндәгеләрне билгеләргә:

- район икътисадына инвестицияләр җәлеп итү, инвестицион һәм инновацион проектларны тормышка ашыру, дәүләт программаларында катнашу;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне, шәхси хуҗалыкларны үстерү;
- кеше капиталын үстерү һәм туплау;
- халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрү;
- район оешма, предприятиеләренең ресурс һәм җитештерү потенциалын максималь рәвештә куллану;
- яңа эш урыннары булдыру;
- җитештерелгән продукциянең сыйфатын арттыру;
- продукция берәмлеген җитештерүгә тотылган чыгымнарны киметү;
- районның хуҗалык итүче субъектларда хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру;
- районның барлык хуҗалык итүче субъектлары тарафыннан энергетик ресурсларны нәтиҗәле һәм экономияле куллану;
- буш җитештерү куәтләреннән максималь файдалану;
- кече һәм урта бизнесны дәүләт һәм муниципаль сатып алулар системасына җәлеп итү;

- конкурентлы сатып алулар нигезендә муниципаль районның берләштерелгән бюджет чыгымнарын киметүне тәэмин итү;

- товарлар, эшләр һәм хезмәтләр җитештерүчеләр өчен тигез конкурентлы шартлар тудыру;

- районның хуҗалык итүче субъектларына адреслы методик, мәгълүмати, консультацион, белем бирү һәм хокукый ярдәм күрсәтү;

- социаль инфраструктура сыйфатын күтәрү, иҗтимагый киңлекләрне үстерү.

2. Иикътисадның барлык субъектларына чыгымнарын һәм керемнәрен бюджет белән тәэмин итүне, товарлар, эшләр һәм хезмәтләр җитештерүне киметмәүне, эш урыннарын саклап калуны, хезмәт хакын вакытында түләүне, бюджетның барлык дәрәҗәләренә салымнарны һәм җыемнарны түләүне;

- авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать предприятиеләренә җитештерү мәйданнарын һәм куәтләрен нәтиҗәле файдалануны тәэмин итъне, җитештерелә торган продукциянең ассортиментын һәм сыйфатын арттыру буенча максатчан эш алып барырга;

- халыкка хезмәт күрсәтүче предприятиеләргә гражданнарның ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерү принцибы нигезендә сыйфатлы хезмәт күрсәтүне тәэмин итъне;

- Саба муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына, казначылык территориаль бүлекләренщ, районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенщ, шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетларына, районның бюджет учреждениеләре җитәкчеләренә бүлеп бирелгән бюджет акчаларын максатчан һәм рациональ файдалануны тәэмин итүне;

- район предприятиеләре һәм оешмалары җитәкчеләренә үз эшчәнлеген анализ һәм финанс-икътисадый планлаштыру нигезендә гамәлгә ашыруны тәкъдим итәргә.

3. Саба муниципаль районы Башкарма комитетына 2019-2021 елларга районның социаль–икътисади үсешен фаразлауның күрсәткечләрен үтәүне даими анализлап торырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р.Ишниязовка йөкләргә.

Саба муниципаль районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов

СОВЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ •

Кушымта
Саба муниципаль районы
Советының 2018 елның
9 ноябрендәге 264 номерлы карарына

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының**
**2019-2021 елларга социаль-икътисадый үсеше фаразы**

| № п/п | Күрсәткеч атамасы | үлчәү берәмлеге | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| | **Авыл хуҗалыгы** | | | | |
| 1.1. | Җитештерү күләме: | | | | |
| | бөртек | мең тонн | 75,3 | 79,1 | 83,1 |
| | бәрәңге | мең тонн | 5,3 | 5,3 | 5,5 |
| | ит | мең тонн | 13,6 | 14,1 | 14,8 |
| | сөт | мең тонн | 58,7 | 60,4 | 62,2 |
| 1.2. | Сату: | | | | |
| | бөртек | мең тонн | 29,2 | 30,0 | 30,9 |
| | бәрәңге | мең тонн | 2,1 | 2,1 | 2,3 |
| | ит | мең тонн | 13,3 | 14,0 | 14,7 |
| | сөт | мең тонн | 53,5 | 56,2 | 59,0 |
| | **Сәнәгать** | | | | |
| 2.1. | Җитештерү һәм сату күләме: | | | | |
| | Крестьян мае | тонн | 580 | 595 | 613 |
| | Майлы сыр | тонн | 2 070 | 2 124 | 2 187 |
| | Коры сыворотка | тонн | 1 285 | 1 319 | 1 358 |
| | Икмәк һәм икмәк-күмәч әйберләре | тонн | 405 | 415 | 428 |
| | Көнбагыш мае | тонн | 2 100 | 2 150 | 2 200 |
| | Кондитер әйберләре | тонн | 103 | 106 | 109 |
| | Агач материаллары | куб.м. | 3 370 | 3 450 | 3 550 |
| | Пеллет (ягулык материалы) | тонн | 2 549 | 2 615 | 2 693 |
| | Агач поддоннар | мең.шт. | 665 | 682 | 703 |
| | **Сәүдә һәм халыкка хезмәт күрсәтү** | | | | |
| 3.1. | Ваклап сату күләме | млн. сум | 2 423,08 | 2 568,08 | 2 737,57 |
| 3.2 | Җәмәгать туклануы әйләнеше | млн. сум | 150,85 | 154,47 | 158,33 |
| 3.3. | Халыкка түләүле хезмәт күрсәтү | млн. сум | 423,02 | 440,79 | 451,37 |

**2019-2021 елларга Саба муниципаль районының социаль-икътисади үсеш фаразын эшләгәндә салынган төп параметрлар**

| Күрсәткеч атамасы | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|
| Кулланучылар бәяләре индексы | 104,3% | 103,8% | 104,0% |
| Районның тулаем территориаль продукт үсеше темпы узган елга карата чагыштырма бәяләрдә | 101,5% | 102,0% | 103,3% |
| Сәнәгать җитештерүе индексы узган елга чагыштырма бәяләрдә | 102,5% | 102,6% | 103,0% |
| Төп капиталга инвестицияләр күләме үсеше темпы узган елга карата чагыштырма бәяләрдә | 103,0% | 104,0% | 105,0% |
| өстәмә бәянең гамәлдәге бәяләргә карата үсеш темпы | 105,5% | 105,4% | 106,5% |
| Узган елга карата уртача айлык хезмәт хакы үсеше темпы | 104,6% | 103,4% | 103,8% |
| Типовой гаилә әгъзасына җан башына минималь куллану бюджетына керемнәрнең күләме | 1,35 раз | 1,40 раз | 1,45 раз |
| Эшсезлек дәрәҗәсе | 0,88% | 0,85% | 0,81% |
| Газ өчен тарифларны арттыру | 103,1% 2019 елның 1 июленнән | 103,0% 2020 елның 1 июленнән | 103,0% 2021 елның 1 июленнән |
| Электр энергиясенә тарифларны арттыру | 106,9% 2019 елның 1 гыйвареннән | 104,0% 2020 елның 1 гыйвареннән | 104,0% 2021 елның 1 гыйвареннән |

## Аңлатма язу

Саба муниципаль районының 2019-2021 елларга социаль-икътисади үсеш фаразы Россия Федерациясе субъекты икътисады һәм икътисады үсешенең сценар шартларын исәпкә алып, алдагы чорда тышкы һәм эчке факторларның киләчәк чорга йогынты ясавын бәяләү нигезендә эшләнгән.

Аерым алганда, социаль-икътисадый вәзгыятьне анализлаганда түбәндәгеләр тикшерелде:

1. Халыкның саны һәм җенси үсеш структурасы динамикасы.
2. Хезмәт базары торышы, эшсезлек күрсәткечләре динамикасы һәм критик хәлләр барлыкка килү мөмкинлеге.
3. Халыкның яшәү дәрәҗәсе (халыкның реаль керемнәре, яшәү минимумыннан түбән кеpемле өлеше, халыкның яшәү минимумы күләменә мөнәсәбәте) һәм аны дифференциацияләү дәрәҗәсе. Куллану дәрәҗәсе (сәүдә әйләнешенең һәм җан башына түләүле хезмәтләрнең күләме динамикасы). Халык тормышы дәрәҗәсендә мөмкин булган диспропорцияләр, аларны булдырмау чаралары һәм ысуллары. Социаль сәясәт, аның юнәлешләре һәм ресурслар белән тәэмин итү.
4. Икътисади үсешнең төп күрсәткечләре динамикасы (районда булдырыла торган тулаем территориаль продукт, сәнәгать җитештерүе, авыл хуҗалыгы, инвестиция эшчәнлеге, товарлар һәм хезмәтләр базары).
5. Икътисадый эшчәнлек төрләре буенча хезмәт җитештерүчәнлеген бәяләү һәм аларның эш белән тәэмин ителүенә динамикасының йогынтысы, халыкның керемнәре һәм хезмәт базары. Икътисадта яңа "үсеш нокталары" барлыкка килү мөмкинлеге һәм булган характеристикалар (эшчәнлекнең һәм җитештерүнең төп табышлы төрләре). Приоритетлы инвестицион проектлар, инвестицияләрне куллану юнәлешләре. Яңа төр товарлар җитештерү перспективалары.
6. Төп фараз күрсәткечләренә ирешү өчен җыелма территориаль ресурслардан файдалануның нәтиҗәлелеге.
7. Икътисадның специализациясе характеристикалары һәм аның түбәндәге юнәлешләр буенча структур үзгәрешләренең мөмкинлекләре:
   - куллану товарлары һәм хезмәтләре җитештерү - арадаш продукция (чимал һәм ярымфабрикатлар) җитештерү;
   - территория икътисадының эчке (Россия) базарына юнәлеш бирү.
8. Кече һәм урта бизнесны үстерү.
9. Саба муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты керемнәренең һәм чыгымнарының балансслылыгы дәрәҗәсе.
10. Экологик хәлне бәяләү- төп пычрату чыганаклары, аларны киметү буенча планлаштырылган чаралар, инвестицияләр чыганаклары.

Фараз Россия Федерациясе икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан җиткерелгән төп сценарий буенча эшләнгән.